КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 апрель г.Казань № 342

«Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын үткәргәндә кешеләр гомере иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казансу елгасы участогында тимер юл күпереннән алып Восстание-Дербышка станцияләре арасында 799 километр Кремль дамбасына кадәр кечкенә суднолар, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт өчен каралган суднолар, шул исәптән гидроцикллар, байдаркалар, ишкәкле көймәләр куллануны түбәндәге вакытларда тыярга:

2019 елның 22 августында 16.00 сәгатьтән 24.00 сәгатькә кадәр;

2019 елның 27 августында 16.00 сәгатьтән 24.00 сәгатькә кадәр.

Бу карарның беренче абзацында күрсәтелгән суднолардан файдалануны тыю «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүдә һәм үткәрдә задействованные судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

әлеге карар белән билгеләнгән тыюны саклау максатларында, Казансу елгасы участокларында кизү торуны тәэмин итәргә;

кертелә торган тыю турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр мнистрлыгы, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, әлеге карар белән кертелгән тыюны саклау максатларында, Казансу елгасы участокларында кизү торуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин